**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**2024 елның 1 ноябре** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең Кәүҗияк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, һәм вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан кала, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Кәүҗияк торак пункты территориясен төзекләндерү (Кәүҗияк торак пунктындагы территориядә үлән чаптыру (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); газ саз 3512 махсуслаштырылган техникасын(үзбушаткыч йөк машинасы) һәм МТЗ-82 тракторын тоту: дизель ягулыгы, дизмай, зап сатып алу.частьлар), МТЗ-82 тракторына чапкыч сатып алу;

2) һәйкәлләр төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (ТР, Сарман муниципаль районы, Кәүҗияк авылы, Совет ур., 14в йорт адресы буенча Кәүҗияк торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар исемлегенә төзәтмәләр кертү һәм яңарту);

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамы буенча Кәүҗияк торак пунктында вак таш түшәмәләрен ремонтлау (вак ташу), мәгълүмат щитларын һәм күрсәткечләрен, үзгәрешле мәгълүмат билгеләрен торгызу (заказчы нигезендә чик буе күрсәткечләрен торгызу).

3. Җыен нәтиҗәләрен Кәүҗияк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы ____________ Ф. Ә. Хөснетдинов